| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ГЛАЗОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ГЛАЗОВО<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 31 октябре № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Глазово авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Лениногорск муниципаль районының Глазово авыл җирлеге Уставына таянып, Лениногорск муниципаль районының Глазово авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. 2019 елның 16 ноябрендә сәгать 8.00 сәгатькә Глазово авыл җирлегенең Глазово авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарылырга тиешле сорауны расларга:

2020 елда Лениногорск муниципаль районының Глазово авыл җирлегенең Глазово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидларыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, күп балалы гаиләләрдән кала, 250 сум күләмендә үзара салым тапшыру һәм аларны түбәндә күрсәтелгән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- суүткәрү милкен карап торуны тәэмин итү;
-территорияне төзекләндерү;
-җирлек территориясен төзекләндерү.

« ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны Глазово авыл җирлегенең Глазово авылында урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Глазово авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы Н.К.Карабаева